Казан шәһәре Совет районы “күп профильле 181 нче мәктәп”
№9 май 2019 нчы ел

# «Күкнең җиденче катында»

**БУ САНДА:**

**Мәктәп яңалыклары.**
**Безнең уңышлар**
**Бирегез мәйдан!**

**Газетабызның май саны**
**Төкле аягың белән!**

## Мәктәп яңалыклары...

### Патриотик җырларны сәхнәләштерү

**7 нче майда патриотик җырларны сәхнәләштерү фестивале булды. Укучылар рус һәм татар телләрендә Бөек Ватан сугышына, туган җиргә багышланган җырлар җырладылар.**

### "Балалар-Бөек Ватан сугышы геройлары" дип аталган тантаналы чара

**8 нче май көнне мәктәбебездә 1-9 сыйныф укучылары өчен "Балалар-Бөек Ватан сугышы геройлары" дип аталган тантаналы чара узды.**

**Бөек Ватан сугышы илебез халкы өчен иң дәһшәтле сынауларның берсе. Аның авырлыгы һәм вәхшилеге кешеләр аңында тирән җәрәхәт калдырды. "Балалар һәм сугыш — дөньяда бу ике капма — каршы әйберләрнең якынаюыннан да куркынычрак нәрсә юк", - дип язды Твардовский очеркларының берсендә. Әмма балалар өлкәннәр белән беррәттән яшәделәр һәм эшләделәр, Җиңүне якынайтыр өчен көчләреннән килгәнчә тырыштылар…**

**Сүз Бөек Ватан сугышы геройлары-балалар турында барды. Аерым хезмәтләре, фашистларга каршы көрәштә күрсәткән батырлыклары өчен аларның күбесенә Советлар Союзы Герое исеме бирелде.**

### "Маэстро" театр студиясенең отчет спектакле

**14 майда «Маэстро» театр студиясенең Ф. Бернетт повесте буенча «Принцесса Кру» дигән отчет спектакле булды. Җитәкчесе: рус теле һәм әдәбияты укытучысы Силантьева Анастасия Вячеславовна.**

**Спектакль бик күңелле узды, укукчылар үзләрен сүхнә осталары итеп күрсәттеләр.**

### Ярминкә

**18 нче май көнне мәктәбебездә ярминкә узды. Укучылар үз куллары белән эшләгән хезмәтләрен, сый-нигъмәтләрен алып килгәннәр иде.**

### Тантаналы линейкалар

**21 нче май көнне мәктәбебез күләмендә тантаналы линейкалар узды.Уку, конкурс алдынгылары бүләкләр һүм грамоталар белән бүләкләнде.**



## Соңгы кыңгырау

23 нче май көнне 9 А , 9 Б сыйныфлары укучылары өчен соңгы кыңгырау яңгырады. Вакыт сизелми дә үтеп китте. Кайчан гына беренче кыңгырау шылтыраган иде, инде менә соңгысы да шылтырады. Соңгы кыңгырау чыгарылыш имтиханнарының башлануы турында хәбәр итә. Иң кечкенә укучылар өчен җәйге каникуллар башлана. Чыгарылыш сыйныф укучылары урамда күккә шарлар очырдылар һәм беренче вальс башкардылар. Балачак артта кала, ә алда олы тормыш көтә...

**Укучылардан хатлар...**

### “ Борчылып утырып кына эш бармый”

Менә уку елы да тәмамланды. Уку елы гына түгел, безнең өчен мәктәп тормышының ишекләре дә ябылды.Күңел әле ышанып бетми. Киләсе елга да шушы мәктәпкә укырга килермен күк. Әле кайчан гына 1 сыйныфка аяк баскан идем бит, юкса. Укырга кергәч тә, яхшы укырга сүз бирәсең. Укый торгач, уйлап куясың инде, “никләр генә сүз бирдем икән” дип. Башта укытучыларның орышуыннан куркып, дәресләрне әзерләп йөрисең.

Хәзер бөтен игътибарыбыз БРИ на юнәлтелгән. Куркыта, борчылам. Әмма борчылып утырып кына эш бармый, шуңа күрә башны бәрә-бәрә укырга кирәк.

Минм дизайнер буласым килә. Ләкин башка һөнәргә тукталдым. Чөнки дизайнерлыкка керер өчен башка фәннән имтихан бирергә кирәк, ә ул фән минем өчен авыррак.

Барлык сыйныфташларыма да киләсе имтиханнарында уңышлар телисем килә.

### “Имтиханнар катлаулы, шуңа 9 дан китәм”

Мәктәптән бик китәсе килми. Ләкин хәзер имтиханнар катлаулана бара, куркыта. Шуңа да 9 сыйныфтан китәргә карар кылдым. Кечкенәдән балалар табибы буласым килсә дә, күңелем икенче һөнәрне сайларга кушты. Пешекче булырга исәбем. Өлкәннәр әйтмешли, тамак та тук була. Шуңа да исәбем шул һөнәрне сайлау.

### БРИ н югары балларга бирүче укучылардан киңәшләр:

- 9 сыйныфта гына түгел, башлангыч классларда ук тырышып укыгыз.
- Ныклап торып системалы рәвештә әзерләнергә, әмма ялга да вакыт таба белергә кирәк.
- Тестларны еш чишәргә
- “Бирә алмыйм, миннән булмыйм” дип үзеңне куркытмаска, киресенчә, үз-үзеңә ышаныч хисе булдырырга.
- Имтихан вакытында ахырга кадәр утыр. Чөнки кайвакыт баштароак таныш булмаган, катлаулы бирем ахырга чишелеш табарга, искә төшәргә мөмкин.
- Артыгын борчылмагыз, чөнки БРИ ны һәр кеше бирә ала!

### Әти-әниләргә ачык хат

Кадерле әти-әниләр!

Сезнең балаларның тиздән имтиханнары. Беләм, сез бик борчыласыз, балаларыгызның имтиханнарын яхшы билгеләргә бирүен телисез. Ләкин шуны истә тотуыгызны телим: укучылар арасында математика кирәкмәгән актер, инглиз теле мәҗбүри булмаган эшмәкәр, химиясез дә яхшы музыкант була алырлык талантлар бар. Әгәр кызыгыз яки улыгыз имтиханнан югары балл ала икән, бик яхшы! Әгәр юк икән, зинһар өчен, аның һәм үзегезнең бәягезне төшермәгез! Киресенчә, аны “ярый, исең китмәсен, бу имтихан гына” дип юатыгыз. Киләчәктә апларны тагын да житдирәк эшләр, сынаулар көтә. Нинди билге алуына карамастан, аңа карата булган мәхәббәтегезнең сүнмәвен әйтеп торыгыз.

## Май бәйрәмнәре

**Ниһаять, май ае да килеп җитте.**

**Май – язның соңгы ае. Ул җәйгә якын тора. Аны чәчәкләр ае дип атар идем мин. Ай башында сиреньнәр, шомыртлар чәчәккә күмелә. Тузганаклар сап-сары чәчәк ата. Май урталарында алмагачлар, чияләр һәм башка җиләк-җимеш агачлары ап-ак чәчәккә күмелә. Алардан бал кортлары бал җыя. Кичен пырылдап май коңгызлары оча. Бала-чага, аларны тоту өчен, ярыш оештыра. Җирне ямь-яшел чирәм каплап ала. Яшь кычытканнар, әрекмәннәр баш калкыта. Карлыганнар, беренчелекне алу өчен, яфрак ярырга ашыгалар. Бөтен җирдә хуш ис, чәчәкләр исе, бал исе. Матурлык. Бер ел фасылы белән дә тиңләштереп булмый торган матурлык.**

## 1 нче май бәйрәме

**Май – илебез байлыгын булдыруда хезмәт иткән бөтен кешеләр бәйрәме.Көн саен үзенең хезмәте белән Ватанын һәм гаиләсен чәчәк аттыручы бөтен халык бәйрәме. Өлкән буын өчен 1 Май элеккечә пролетар бердәмлекне гәүдәләндерә, ә яшьләр өчен –табигать һәм кешелек көчен тудырган язгы чәчәк ату чоры.**

**1 Май бәйрәме беренче тапкыр 1890 елда Варшавада, ә 1891 елда Санкт-Петербургта бәйрәм ителә.**

**Бәйрәм тарих төсмерен саклап калып, бүген дә бөтен кешелек дөньясы өчен элеккеге кебек үк хезмәт ияләре бәйрәме, хезмәт, тынычлык, үзара татулык бәйрәме булып кала. Ни генә булмасын, 1 май чын-чынлап яз килүен белдерә. Нәкъ менә бу айда алмагачлар, шомыртлар ап-ак чәчкәгә күмелә. Бар җиһан гүя әкияти дөньяны хәтерләтә.Барыгызны да яшел чирәмнәре шытып чыккан, каеннары яфрак ярган яз бәйрәме белән котлыйбыз. Яз сулышы күңелегезгә нур өстәсен. Бәхет кояшы көннән-көн яктыра барсын, йөрәгегез хискә тулсын, һәрвакыт яшь булсын. Гомерегез дә яз көне кебек якты, кояшлы, аяз күкле, нурлы булсын!**

## 9нчы май-Бөек Җиңү көне

**Бу сүзләрнең төгәл эчтәлеген, тулы мәгънәсен, чын җиңү хисен бүгенге көндә бары тик шул сугышта катнашкан ветераннарыбыз һәм сугыш ачысын тойган әби-бабайларыбыз гына беләдер, дип уйлыйм. Әлеге сугышта җиңү яулый алганнары өчен без дә алар белән бергә бәйрәм итәбез, аларның шатлыгын уртаклашабыз, аларга саулык-сәламәтлек телибез.**

**Нәрсә соң ул сугыш? Бу сорауга җавапны белмәвең яхшырак. Әмма ләкин бүгенге көндә дә сугышлар булып тора, кешеләр һәлак була, бер гөнаһсыз кешеләрнең тормышлары өзелә. Кемдер байлык өчен, кемдер көнләшүдән, кемдер үч белән, кемдер үзенең өстенлеген күрсәтергә теләп, кемдер үзен саклап калу өчен...**

**Бөек Ватан сугышы исә Икенче Бөтендөнья сугышының зур гына бер өлеше ул. Сугышның иң төп сәбәбе - Гитлер Германиясенең нацистик (үз милләтен өстен куйган) һәм реваншистик карашы.Советлар Союзының әлеге сугышта җиңүе белән бу зур гына сугыш тәмамланган дип тә әйтергә була. Әмма бу җиңү Советлар Союзына һәм аның союздаш илләренә бик кыйммәткә төшкән. Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы гына да 27 миллионнан артык кешесен югалткан. Шул исәптән 4-5 миллион чамасы милләттәшләребез һәлак булган.Әлеге сугыш тәмамлануга 74ел тулды. Сугышның ни икәнен тагын бер тапкыр хәтердә ныгытырга мөмкин.. Киләчәктә шундый сугышларны булдырмыйк! Бар халык бер-берсен тигез**

күрсен, көнчелек һәм хөсетлек, үч һәм нәфрәт хисләре беркайчан да күңелебезгә үтеп кермәсен. Яныгыздагы кешегә карап елмаегыз, аны кочаклап алып бәйрәм белән котлагыз. Бу сугышта фашист нацистлары җиңү яулаган булса мин дә, сез дә, сезнең якыннарыгыз да булмас иде, мөгаен. Шатланыгыз... Тыныч зәңгәр күк йөзенә, анда балкыган кояшка карап сөенегез. Һәм киләчәктә дә тормышыбыз шундый аяз һәм тыныч булсын!

## Җәйге ялда

Рәхәт тә соң җәй көннәре! Өстеңдә — җиңел кием, аягыңда да авыр табанлы ботинкалар түгел. Кояш белән бергә торып, мәктәпкә йөгерәсең дә юк. Ятасың иркәләнеп йомшак юрган астында. Җәен әле аның йокысы да тизрәк туя. Югыйсә кыш буе хыялланасың: эх, җәй генә җитсен, туйганчы бер йоклар идем, дисең. Инде укулар бетеп, күпмедер вакыт узуга ук, көнеңне, сәгатеңне йокыга гына әрәм итәсең килми башлый. Күңел гел каядыр җилкенеп, ашкынып тора. Юрган астындагы иркәлек тә бераздан туйдыра. Кешедән алда су буена төшеп, балык каптырасың килә, җиләккә иң мул чагында, чиләк-чиләк тутырып булганда йөрергә тырышасың. Менә бүген барам да башка кирәкми, дигән булсаң да, яңадан ике, өч, биш тә урманга йөгерәсең.

Җәй рәхәт. Җиләк, чәчәк тәме килә. Әйе, рәхәт.

Җәең авылда, бакчада узса, аеруча рәхәт. Ныгып, тазарып, үзең дә яшелчә кебек өлгереп, мәктәпкә киләсең.

Эх, яратам да соң бу җәйге каникулларны!

И күңелле җәй көнендә,

Табигать кочагында

Менә шуны истә тоту,

Кирәктер шул чагында.

Эссе чакта, коры чакта

Урманда ут якмагыз

Агачларны сындырмагыз

Кош оясын ватмагыз

Суларны да пычратмагыз

Пыяла, чүп атмагыз.

- Табигать ул — безнең әни.

Табигатьне саклагыз!


**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576

**Тираж** – 50 экз.
**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Корчагина Яна
**Редколлегия әгъзалары:**
Мәхмүтова Мәдинә, Хәйриев Самат, Вәлиева Диләрә, Мельникова Аделина, Мәхмүтова Мәликә, Хөснетдинова Камелия


***

Хөрмәтле укытучылар, кадерле укучылар! Уку елы да ахырына якынлашты. Сезгә киләсе уку елларында зурдан-зур уңышлар, саулык, аң-белем теләп калабыз! Барыгызга да киләчәктә уңышлар елмайсын,юлларыгыз ак булсын!

